**Казан шәһәре Башкарма комитетының**
**2026 елның 22 апрелендәге 1335 номерлы карары**

**«Россия – Ислам дөньясы: KazanForum» XVII халыкара икътисади форумын уздыру кысаларында Казан шәһәренең урам-юл челтәре буенча транспорт чаралары хәрәкәтен чикләү турында**

«Россия – Ислам дөньясы: KazanForum» XVII халыкара икътисади форумын әзерләү һәм уздыру чорында иминлекне тәэмин итү максатыннан, 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында»гы федераль законга, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2013 елның 31 маендагы 372 номерлы «Төбәк әһәмиятендәге яки муниципальара, җирле әһәмияттәге автомобиль юлларында транспорт чаралары хәрәкәтен вакытлыча чикләүне яисә вакытлыча туктатып торуны гамәлгә ашыру тәртибен раслау турында»гы карарына таянып:

1. **Карар бирәм**:

1.1. кирәк булганда, түбәндәге участокларда, «Спорт һәм социаль проектлар дирекциясе» автоном коммерцияле булмаган оешма билгеләгән форма буенча махсус рөхсәт кәгазьләре белән җиһазландырылган клиент төркемнәренең транспорт чараларыннан кала, транспорт чаралары хәрәкәтен чикләүне кертергә:

1.1.1. Пушкин урамы буйлап, Карл Маркс урамыннан алып Большая Красная урамына кадәр һәм Карл Маркс урамындагы 110 номерлы муниципаль парковка участогында, 2026 елның 11 маенда 20:00 сәгатьтән 2026 елның 15 маенда 20:00 сәгатькә кадәр;

1.1.2. Һади Такташ урамы буйлап, Спартак урамыннан алып Марсель Сәлимҗанов урамына кадәрге участокта, 2026 елның 13 маенда 20:00 сәгатьтән 2026 елның 15 маенда 20:00 сәгатькә кадәр;

1.1.3. Һади Такташ урамы буйлап, Нурсолтан Назарбаев урамыннан алып Туфан Миңнуллин урамына кадәр, 2026 елның 12 маенда 20:00 сәгатьтән 2026 елның 15 маенда 23:59 сәгатькә кадәр;

1.1.4. Альберт Камалиев проспекты буенча парковка зонасында, «Казан» халыкара ат спорты комплексының үзәк керү төркеме каршында, 2026 елның 14 маенда 20:00 сәгатьтән 2026 елның 16 маенда 23:59 сәгатькә кадәр;

1.2. Казан шәһәре Башкарма комитетының Транспорт комитетына (А.В.Сидоров):

1.2.1. вакытлыча юл билгеләрен урнаштыру һәм гамәлдәге юл билгеләрен каплау буенча чаралар оештырырга;

1.2.2. транспорт чаралары хәрәкәтен вакытлыча чикләү турындагы мәгълүматны Татарстан Республикасы Транспорт һәм юл хуҗалыгы министрлыгының Интернет челтәрендә Татарстан Республикасының «Татарстан Республикасы рәсми порталы» дәүләт мәгълүмат системасы составына керә торган рәсми сайтында урнаштырырга;

1.2.3. кыска вакытлы аренда хезмәте күрсәтә торган электр самокатлары (WHOOSH һәм MTC.URENT) һәм велосипедлар («Яшел шәһәр») операторлары белән берлектә әлеге карарда күрсәтелгән участокларда шәхси мобильлек чараларын куеп торуны һәм аларның хәрәкәтен тыю эшен оештырырга;

1.3. Казан шәһәре Башкарма комитетының Тышкы төзекләндерү комитетына (А.М.Шайнуров) Казан шәһәре Башкарма комитетының Вахитов һәм Идел буе районнары администрациясе (А.И.Салихов) һәм Казан шәһәре Башкарма комитетының Совет районы администрациясе (Р.Р.Фәтхетдинов) белән берлектә юлларны йөк техникасы яки таранга каршы блоклар белән ябу эшен оештырырга;

1.4. әлеге карарны «Муниципаль хокукый актлар һәм башка рәсми мәгълүмат» челтәр басмасында (www.docskzn.ru) бастырырга, Казан шәһәре җирле үзидарә органнарының рәсми порталында (www.kzn.ru) һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (www.pravo.tatarstan.ru) урнаштырырга.

2. **Тәкъдим итәм**:

2.1. «Спорт һәм социаль проектлар дирекциясе» автоном коммерцияле булмаган оешмасына (М.С.Денисов) Россия Федерациясе Эчке эшләр министрлыгының Казан шәһәре буенча идарәсенең Юл хәрәкәте иминлеге дәүләт инспекциясе бүлегенә әлеге карарның 1.1 пунктчасында күрсәтелгән рөхсәтнамә үрнәкләрен тапшырырга;

2.2. Россия Федерациясе Эчке эшләр министрлыгының Казан шәһәре буенча идарәсенә (Р.Д.Габитов) әлеге карар нигезендә Казан шәһәре урам-юл челтәренең югарыда күрсәтелгән участокларында юл хәрәкәте иминлеген саклауны һәм оештыру-көйләү гамәлләрен башкаруны контрольдә тотуны тәэмин итәргә;

2.3. Казан шәһәре Думасы аппаратының Мәгълүмат-аналитика идарәсенә (В.А.Казанцев) урам-юл челтәренең күрсәтелгән участокларында транспорт чаралары хәрәкәтен һәм аларны куеп торуны вакытлыча чикләүне кертү турында массакүләм мәгълүмат чаралары аша хәбәр итәргә.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Казан шәһәре Башкарма комитеты Җитәкчесе урынбасары И.С.Шакировка **йөклим**.

**Җитәкче** **Р.Г.Гафаров**